# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл
авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**11.11.2021 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45- ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 11 оноябрендә узган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегендә халык җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

«Сез, 2022 елда, Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бәйрәм чараларын үткәрү, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Учук», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел»га бүләк һәм сувенир продукция сатып алу буенча хезмәт күрсәтү, аппаратура алу);

- Якты Күл авылында урамнарны яктырту (лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (чит оешмалар тарафыннан юлларны кардан чистарту буенча хезмәтләр күрсәтү)

РИЗА КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 53 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенда катнашып тавыш биргән гражданнар саны - 39кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 37, «КАРШЫ» позициясе өчен 2 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре- гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2022 елда, Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы

студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум  күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп,  үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бәйрәм чараларын үткәрү, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Учук», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел»га бүләк һәм сувенир продукция сатып алу буенча хезмәт күрсәтү, аппаратура алу);

- Якты Күл авылында урамнарны яктырту (лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (чит оешмалар тарафыннан юлларны кардан чистарту буенча хезмәтләр күрсәтү)

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт, Якты Күл авылы, Якты Күл урамы, 15 йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы                                        Г.М.Төхвәтуллина